ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.01.2020 г.Мензелинск № 1

**ТР Минзәлә муниципаль районының “Солнышко” Иске Маҗын балалар бакчасы МББУ Уставын яңа редакциядә раслау һәм эш режимын үзгәртү турында**

Россия Федерациясенең Гражданлык кодексын, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131 номерлы Федераль законын, “Россия Федерациясендә мәгариф турында” 2012 елның 29 декабрендәге 273 Федераль законын кулланып, “Мәктәпкәчә белем бирү учреждениесендә Типовой нигезләмәне раслау турында” 2011 елның 27 октябрендәге №2562 номерлы Россия Федерациясненең Мәгариф һәм фән министрлыгының боерыгы нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2020 елның 9 гыйнварыннан 5 көнлек эш атнасы режимына күчәргә һәм эшли башларга.
2. ТР Минзәлә муниципаль районының “Солнышко” Иске Маҗын балалар бакчасы Муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем бирү учреждениесе Уставын яңа редакциядә расларга.
3. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының “Солнышко” Иске Маҗын балалар бакчасы МББУ мөдире Новичкова Татьяна Василиевнага әлеге карар кабул ителгәннән соң өч эш көне дәвамында юридик затларның дәүләт теркәвен башкаручы органга (Россия Федераль Салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча 18 нче номерлы районара инспекциясе) яңа редакциядә Уставны раслау турында билгеләнгән тәртиптә хәбәр итү вәкаләтен бирергә.
4. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Башкарма комитетының 22.03.2019 елдагы 301 номерлы карарын көчен югалткан дип танырга.
5. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Минзәлә муниципаль районының “Мәгариф бүлеге” Муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе Н.С.Габдуллинга йөкләргә.

Җитәкче К.Р. Нәҗмиев.